КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 апрель г.Казань № 302

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2015 ел, 26 март, 187 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 май, 441 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Системаның дәүләт заказчысы һәм техник операторы итеп - «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформациясе үзәге» дәүләт казна учреждениесен, аңа Системага техник ярдәм, методик озата бару һәм үстерү чараларын үткәрүне тәэмин итү өлешендә тиешле вәкаләтләр биреп;»;

1 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 25 гыйнвар, 23 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 май, 441 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«техник оператор вазыйфаларын «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформациясе үзәге» дәүләт казна учреждениесе башкара;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин